МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02. 03. 2021 г. Казань № 315

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 13.11.2020 елның № 1954 боерыгы белән расланган, Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ Регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерам:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 13.11.2020 ел, № 1954 боерыгы белән расланган Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ Регламентына Кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр М.Н. Садыйков

02.03.2021 № 315
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 13.11.2020 ел № 1954 боерыгы белән расланган, Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ Регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Пункт 2.5:

«Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасында унынчы абзацны «якын туганлык элемтәләренең булмавын раслаучы документлар (гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, туу турында таныклык, никахлашу (аерылышу) турында таныклык һ. б.)» «чит ил дәүләте компетентлы органнары тарафыннан бирелгән, һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе» сүзләре белән тулыландырырга.

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль закон № 63-ФЗ; РФ ГК 37 ст.; Федераль закон № 210-ФЗ 7 ст.; № 48-ФЗ закон 19, 21 ст.ст.»;

Пункт 2.6 «Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

опекага алынган зат исемендә булган милеккә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермә (ЕГРН) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсендә).

опекунның (попечительнең) һәм рента бирүче белән гаилә яки якын туганлык элемтәләре булмавын раслаучы белешмәләр (гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, туу турында таныклык (өземтә), никахлашу (аерылышу) турында таныклык (өземтә) һ. б.).

Мөрәҗәгать итүченең бирергә хокуклы документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алынырга тиешле документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган каралмаган документларны һәм мәгълүматларны тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру;

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү кертүне раслаучы документлар, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, тапшыру;

№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне;

пункт 3.4.1 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге запросларны җибәрә:

- гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарга);

- опекага алынган затның милкендә булган милеккә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермә (ЕГРН) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсендә);

- опекунның (попечительнең) һәм рента бирүче белән гаилә яки якын туганлык элемтәләре булмавын раслаучы белешмәләр (гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, туу турында таныклык (өземтә), никахлашу (аерылышу) турында таныклык (өземтә) һ. б.).

Ведомствоара запрос электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба - СМЭВ) каналлары буенча төзелә һәм җибәрелә (алга таба - СМЭВ).

СМЭВ каналлары буенча ведомствоара запрос төзү һәм җибәрүнең техник мөмкинлеге булмаганда, ведомствоара запрос кәгазьдә почта аша, факс буенча, почта яки курьер илтүе аша җибәрелә.

Ведомствоара запрос № 210-ФЗ Федераль законның 7.2 статья таләпләренә туры китереп төзелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара запрослар җибәрү.»